## Олимпиадага әзерләнү өчен минимум

### 1 сыйныф

1.Татар алфавиты.

2.Татарстан шәһәрләре. Татарстан районнары

3.Хайваннар һәм кош-кортларның татарча атамаларын белү

4.Яшелчәләр һәм җиләк җимешләрнең татарча атамалары

5.Төсләрнең татарча атамалары

6.Саннарның татарча атамалары

7.Татар халык әкиятләренең исемнәрен, авторларын, геройларын белү

### 2 сыйныф

1. Авазлар. Әйтелгән сүздән аерым сузык яки тартык авазны аерып алу. Сүздәге авазларның санын һәм эзлеклелеген билгеләү. Бер яки берничә аваз белән аерыла торган сүзләрне чагыштыру.

2. Сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны, басымлы һәм басымсыз сузыкларны, яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны аеру.

3. Иҗек. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, сүз басымын билгеләү.

4. Татар алфавитын, андагы хәрефләрнең урнашу тәртибен белү, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру һәм кирәкле мәгълүматны эзләп табу.

5. Сүзләргә фонетик-график (аваз-хәреф) анализы ясау

6. Дәрестә, мәктәптә, тормыш-көнкүрештә, төрле яшьтәге таныш яки таныш булмаган кешеләр белән телдән аралашканда, тел берәмлекләрен урынлы файдалану,

### 3 сыйныф

1. “Фонетика, графика һәм орфоэпия” бүлекләре буенча

Калын һәм нечкә сузыкларны аеру, татар телендәге басымын дөрес куеп әйтү (уку). Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аеру; ъ һәм ь хәрефләре булган сүзләрне дөрес уку һәм язу (кульяулык, көньяк); я, ю, е хәрефләрен дөрес язу. Сүзләрдәге авазлар һәм хәрефләрне аеру, аларның санын һәм төрләрен күрсәтү. Сөйләмдә татар әдәби теленә хас булган орфоэпик нормаларны үтәү.

2.“Сүз төзелеше” бүлеге буенча

Сүзләрнең тамырын һәм кушымчасын билгеләү, тамырдаш сүзләр, кушма һәм парлы сүзләрне табу. Мәгънәсен ачыкларга кирәк булган сүзләрне сүзлектән табып әйтү (күрсәтү).

3.“Морфология” бүлеге буенча

Сүз төркемнәреннән исем, фигыль һәм сыйфатларның мәгънәләрен аңлап, җөмлә эченнән табу. Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формаларын аеру, фигыльләрнең юклык һәм заман кушымчаларын билгеләү, сыйфатланмышны табу,

аның сыйфат белән бәйләнешен күзәтү. Өйрәнелә торган сүз төркемнәре кергән мәкаль-әйтем, табышмакларны ятлау (әйтү) һәм аларны язу.

4.“Синтаксис” бүлеге буенча

Җөмләнең баш кисәкләрен билгеләү, аларның урнашу тәртибен күзәтү. Җөмлә кисәкләре һәм сүз төркемнәре дигән төшенчәләрне аеру.

**4 сыйныф**

1.Сүз

Әйтелеш һәм мәгънә бердәмлеге буларак сүз, аның туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Синонимнар, омонимнар һәм антонимнар. Сүзлекләр.

2.Сүз төзелеше һәм ясалышы

Сүзнең нигезе һәм аның төрләре. Кушымчлар. Татар һәм рус телләрендә сүзләргә кушымчаларның ялгану тәртибе.

3.Морфология

Исем турында өйрәнгәннәрне искә төшерү. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр. Исемнәрнең килеш белән төрләнүе турында мәгълүмат бирү. Сыйфат турында белгәннәрне искә төшерү һәм ныгыту. Синоним һәм антоним сыйфатлар. Аларны сөйләмдә дөрес куллану. Сыйфатларның җөмләдәге роле. Татар телендә сыйфат белән сыйфатланмышның бәйләнеше. Сан. Аның мәгънәсе, сораулары, сөйләмдә дөрес куллану. Сан белән саналмышның бәйләнеше. Микъдар саннары. Алмашлык. Зат алмашлыклары. Аларның мәгънәсе, килеш белән төрләнеше. Фигыль турында өйрәнгәннәрне искә төшерү, аның заманнары. Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше, аларның сөйләмдә дөрес кулланылышы. Рус телендәге фигыльләрнең заманнары һәм зат-сан белән төрләнешендәге үзенчәлекләр.

4.Синтаксис

Өйрәнелгән сүз төркемнәрен кулланып, сүзтезмә һәм җөмләләр төзү, аларны сөйләмдә дөрес куллану. Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре: хикәя, сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләр. Җөмләнең баш кисәкләрен билгели белү. Аергыч турында мәгълүмат бирү, аларны сөйләмдә дөрес куллану. Русча җөмләләрне татарчага тәрҗемә итү. Татар телендә җөмләдәге сүз тәртибе (ия белән хәбәрнең, аергыч белән аерылмышның урыннары).

**5 сыйныф**

1.“Фонетика, графика һәм орфоэпия” бүлекләре буенча

Аваз һәм хәреф арасындагы аерманы аңлау, өйрәнгән күләмдә авазларга характеристика бирү, алфавиттагы хәрефләрнең урынын белү, аны гамәли эштә куллану. Сузык авазлар һәм хәрефләр. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны дөрес әйтү. Сузык авазларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Татар һәм рус телләрендә [а], [э], [о], [ө], [ы] авазларның әйтелеше, бу сузыкларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Тартык авазлар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. [w],

[гъ], [къ], [х], [ч] тартыкларын дөрес әйтү, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Татар теленең үзенчәлекле тартыклары [җ], [ң], [һ].

2.Сүз

Әйтелеш һәм мәгънә бердәмлеге буларак сүз, аның туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Сүз тамыры. Сүз ясагыч кушымчалар,тамырдаш сүзләр, кушма һәм парлы сүзләр. Синонимнар, омонимнар һәм антонимнар.

3.“Сүз төзелеше” бүлеге буенча

Кушымчлар.Сүзләрнең тамырын һәм кушымчасын билгеләү, тамырдаш сүзләр, кушма һәм парлы сүзләрне табу.

4.“Морфология” бүлеге буенча

Сүз төркемнәреннән исем, фигыль һәм сыйфатларның мәгънәләрен аңлап, җөмлә эченнән табу. Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формаларын аеру, фигыльләрнең юклык һәм заман кушымчаларын билгеләү, сыйфатланмышны табу, аның сыйфат белән бәйләнешен күзәтү.

5.“Синтаксис” бүлеге буенча

Җөмләнең баш кисәкләрен билгеләү, аларның урнашу тәртибен күзәтү. Җөмлә кисәкләре һәм сүз төркемнәре дигән төшенчәләрне аеру.

**6 сыйныф**

1.Фонетика һәм орфоэпия турында гомуми төшенчә. Татар телендә сузык һәм артык авазлар. Сингармонизм законы: рәт һәм ирен гармониясе.

2.Тартык авазлар классификациясе. [къ], [к] һәм[гъ], [г] тартык авазлары. [һ] һәм[х] тартык авазлары. [w] һәм[в] тартык авазлары. [н] һәм[ң] тартык авазлары. [’] (һәмзә) тартыгы.

3.Татар телендә иҗек, иҗек калыплары.Сүзләрне юлдан-юлгакүчерү. Сүз басымы. Интонация.

4.Сузык аваз хәрефләре. О, ө, е, э хәрефләренең дөрес язылышы. Икешәр аваз кушылмасын белдергән е, ю, я, хәрефләренең дөрес язылышы.

5.Тартык аваз хәрефләре.ъ һәм ь хәрефләренең дөрес язылышы.

6.Лексикология. Лексика һәм лексикология турында төшенчә. Сүзнең лексик мәгънәсе, аны аңлату юллары.

7.Синоним. Антоним. Омоним.

8.Фразеологизмнар. Фразеологик әйтелмәләрне сөйләмдә куллану.

9.Текст буенча комплекслы эш: аңа исем бирү, җөмлә һәм текст кисәкләренең эзлеклелеген аңлау.

10.Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре.

11. Сүз төркемнәре.

**Татар төркемнәре өчен темалар (темы устного тура для татарских групп)**

**1 класс:**
1. Үзеңнең гаиләң турында татарча  сөйлә.
2. Укытучылар турында  бер татар шагыйренең шигырен сәнгатьле сөйлә.

**2 класс:**
1. Якын дустың турында сөйлә.
2. Белем алу турында 5 мәкаль әйт.

**3 класс:**
1. Үзең яшәгән шәһәр (авыл) турында сөйлә.
2. Әниләр  турында 5 мәкаль әйт.

**4 класс:**
1. Табигатьне саклау өченниләр эшләргә кирәк?
2. Үзең укыган бер хикәя турында сөйлә. Авторы кем? Бу хикәяне укыгач нинди фикерләр туды?

**5 класс:**
1. Россия герое Марат Әхмәтшин турында Син ниләр беләсең? Аның турында сөйлә.
2. 2. Г.Тукайның кайсы шигырендә кәҗә рәхмәтне кемгә һәм ни өчен укый? Синең рәхмәт укырлык яхшы эшләр эшләгәнең бармы? Фикерләреңне туплап (8-9 җөмлә) сөйлә.

**6 класс:**
1. Татар халык авыз иҗаты турында сөйлә.
2. Син су буенда балык тотканда кармагыңа алтын балык эләктердең. Аңардан ниләр сорарсың һәм ни өчен?

## Минимум знаний для выполнения олимпиадных заданий для русскоязычной группы

### 1 класс

1. Звуки и буквы татарского языка
2. Имена числительные
3. Слова, отвечающие на вопросы Кем? Нәрсә?
4. Цвета
5. Множественное число имён существительных

### 2 класс

1. Звуки и буквы татарского языка
2. Закон сингармонизма
3. Антонимы
4. Имена числительные
5. Времена года
6. Множественное число имён существительных

### 3 класс

1. Звуки и буквы татарского языка
2. Закон сингармонизма
3. Антонимы
4. Имена числительные
5. Времена года
6. Множественное число имён существительных

### 4 класс

1. Звуки и буквы татарского языка
2. Закон сингармонизма
3. Антонимы
4. Имена числительные

5. Название городов и рек

6. Множественное число имён существительных

7. Время глаголов

8. Отрицательная форма глаголов

**5 класс**

1. Звуки и буквы татарского языка

2. Закон сингармонизма

3. Антонимы

4. Имена числительные

5. Профессии

6. Животные и их детёныши

7. Множественное число имён существительных

**6 класс**

1. Антонимы.

2. Местоимения

3. Закон сингармонизма.

4. Вводные слова.

5. Лексика по теме “Части тела”.

6. Словообразование

7. Прошедшее время.

**Рус төркемнәре өчен темалар (темы для русскоязычных групп):**

**1 класс:**

1. Расскажи про своего друга на татарском языке.

2. Что растет в огороде? Расскажи про тот овощ, который ты любишь больше остальных.

**2 класс:**

1.Расскажи про твой класс на татарском языке.

2. Составь рассказ “Мое любимое произведение”.

**3 класс:**

1.Расскажи о посещении музея.

2.Составь рассказ “Мой любимый урок”.

**4 класс:**

1. Расскажи о своей семье

2. Составь рассказ “Берегите природу!”.

**5 класс:**

1. Расскажи про свой родной город (деревню).

2. Составь рассказ “Мое путешествие”.

**6 класс:**

1. Расскажи, что ты знаешь о Герое России М.Р.Ахметшине.

2. Назови не менее 5 татарских народных пословиц про знание.